РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423732, село Тюково,
ул. Ленина, дом 61/2,
Тел. 3-44-61
Email: tuk-akt@yandex.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423732, Түке авылы,
Ленин ур., 61/2 нче йорт.
Тел.3-44-61

Email: tuk-akt@yandex.ru

# РЕШЕНИЕ

«24» март 2025 ел №4

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Түке авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Түке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясы нигезендә, Совет Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге

карар итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Түке авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) 2025 елның 31 мартыннан да соңга калмыйча бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга, торак пунктлар территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Түке җирлегенең түбәндәге адреслары буенча халыкка җиткерергә:

Түке ав. Ленин ур., 61/2 йорт (административ бина);

Зөбәер ав., Үзәк ур., 32 йорт (мәдәният йорты бинасы).

Чәчер ав.Үзәк ур, 31 йорт ( авыл клубы)

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Түке авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Р.М.Нуртдинов